ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

11.01.2021 г. № 02

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 23 гыйнварындагы 90 номерлы карары белән расланган балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, карар бирәм:

1. Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 23 гыйнварындагы 90 номерлы карары белән расланган балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны кабул итү кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә, балаларны яңа составта өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль ведомствоара комиссияне расларга.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Н. Бәдретдиновка йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 11 нче гыйнвар
02 нче номерлы карары белән расланган
1 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 23 гыйнварындагы 90 номерлы карары белән расланган балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны кабул итү кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләр

1. 2015 елның 23 гыйнварындагы 90 номерлы карарның преамбуласында «Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 29 августындагы 1008 номерлы боерыгы белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. «Гомуми нигезләмәләр» I бүлегендәге 10 абзацны төшереп калдырырга.

3. «Кабул итү тәртибе» II бүлегендәге 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Белем алу өчен Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән балаларның эшчәнлек режимына карата таләпләрнең артуына китерә торган оешмага кабул итү турында гариза биргән очракта, әлеге гариза муниципаль ведомствоара комиссия каравына җибәрелә.».

4. «Өстәмә белем бирү оешмасына кабул итүдән баш тарту сәбәпләре» III бүлегендәге 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Балалар эшчәнлеге режимына карата Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләрне арттыру.».

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 11 нче гыйнвар
02 нче номерлы карары белән расланган
2 нче кушымта

Балаларны өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль ведомствоара комиссиясе составы

| | | |
|---|---|---|
| Бәдретдинов Илнар Наил улы | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Гыйниятуллин Рамил Мәүлет улы | - | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгы, рәис урынбасары; |
| Аитова Айгөл Фәргать кызы | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре буенча идарәсе башлыгы; |
| Клипачев Александр Сергеевич | - | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы; |
| Мөбарәкшина Гүзәл Мөхәррәм кызы | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы. |